**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы**
**Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында гражданнар җыены**

**К А Р А Р**

27 ноябрь 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында
гражданнарга үзара салымын кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Уставының 22 ст., Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләре буенча гражданнар җыены уздыру турында" 2025 елның 17 ноябрендәге 2 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә. 1-2 нче төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны һәм аларга тиңләштерелгәннәрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, көндезге уку формасында укучы студентларны, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затларны түләүдән азат итәргә, ә күпбалалаы гаиләләргә түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә һәм үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә.

1. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Тагай авылында мәгълүмат стенды сатып алу һәм урнаштыру – 1данә, суга батыру насосы сатып алу, печән чабу)

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;(юлларны кардан чистарту).

3. Урамнарны яктырту җайланмасы (Тагай авылында урам яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Абалач авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге башлыгы И.Н. Әкбәров